**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән олимпиада биремнәренең ҖАВАПЛАРЫ**
**2025-2026 нчы уку елы**
**9 нчы сыйныф**

**Максималь балл –66**

## I. ТЕСТ (20 балл)

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **2** | **1** | **4** | **4** | **4** | **2** | **1** | **3** | сызык | мәсьәләне |

**III. Теоретик бирем.**
Тартыклар охшашлануы турында языгыз. Фикерегезне мисаллар белән дәлилләгез. **(8 балл)**
Укучы мәктәп программасы, дәреслекләрдә бирелгән материалны мөмкин кадәр тулы чагылдырган очракта, мисаллар белән дәлилләгәндә, биремгә иң югары балл куела. Төгәлсезлекләрнең күләменә карап, баллар саны киметелә. Мәгълүмат бөтенләй булмаган очракта, укучыга 0 балл куела.

## III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

Фигыльләр һәм аларның төркемчәләрен тәңгәллек белән күрсәтегез**,** җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

| ФИГЫЛЬ | ТӨРКЕМЧӘСЕ |
|---|---|
| А) соңлаган яз | 1) исем фигыль |
| Ә) урындыкка утыру | 2) хәл фигыль |
| Б) уйлар таралгач | 3) хикәя фигыль |
| В) куелмаган иде | 4) сыйфат фигыль |
| Г) әйткән булса | 5) шарт фигыль |

**Җавап : 41235**

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Фразеологик әйтелмә барлыкка килерлек итеп, фигыльләр өстәп языгыз. **(5 балл)**

Борчак **сибү/аттыру**
Кызыл кар **яугач**
Балтасы суга **төшү**
Трай **тибү**
Тетмәсен **тетү**

2. Текстты укыгыз һәм <...> тамгасы урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(2 балл) һәр төшеп калган хәреф – 0,5 балл**

1) Авылның үзенә генә хас тавышлар белән тулган изге тынлыгын бернинди бөек симфонияләр, моңлы көйләр дә уза алмый. 2) Бөтенесе йөрәккә якын, бөтенесе якты нур белән, ила <**һ**>и тынлык, куанычлы моң белән өр<**е**>телгән. 3) Шуңа күрә авыл кешесенең шатлык-куанычлары да мәңге онытылмаслык, борчу-газаплары да йөрәген сулкылдатырлык тирән. 4) Әгәр шулай булмаса, авылыннан китеп, чит-ят җирләрдә гомер кичерүче кешеләр аны хәтерләреннән жуяр иде. 5) Юк шул, оныта алмый <**а**>дәм баласы туган төбәген. 6) Аның хәтерендә ялан тәпи баскан чирәмле ишегалды, аунап-тәгәрәп үскән болыннары, су кое<**н**>ган күлләре, челтерәп аккан чишмә суларының тәмнәре, җиләк-җимеш тулы әрәмәләре, ап-ак кыш-лары торган саен жетерәк, дулкынландыргычрак булып яңара. (*Ф. Садриев*)

3. Тексттан Европа алынмасын табып, күчереп языгыз. **(2 балл)**
**симфонияләр**
4. Тексттан синонимик парлы сүзләрне күчереп языгыз, кайсы сүз төркеменә карауларын билгеләгез. **(4 балл)**
**шатлык-куанычлары – исем , борчу-газаплары - исем, чит-ят - сыйфат, аунап-тәгәрәп - фигыль**
5. 5-6 нчы җөмләләрдән әдәби нормадан читләшкән сүзне күчереп языгыз. (**2 балл**)
**дулкынландыргычрак**
6. Тексттан *тын* сүзенә тамырдаш сүзне табыгыз, үзегез тагын ике тамырдаш сүз уйлап языгыз. (**3 балл**)
**тын – тынлык - тыныч - тынычлану**
7. Бишенче җөмләне туры тәртипкә үзгәртеп языгыз. **(5 балл)**
**Юк шул, адәм баласы туган төбәген оныта алмый.**
8.“*Авылым иртәсе*” темасына 9-10 җөмләдән торган инша языгыз. (**10 балл**)